ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә
кабул ителде

## 1 статья

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.21 статья өстәргә:

«2.21 статья. **Режим (төп әзерлек дәрәҗәсе) кысаларындагы чараларны гамәлгә ашыруны күздә тотучы Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү**

1. Татарстан Республикасы территориясендә билгеләнгән режим (төп әзерлек дәрәҗәсе) кысаларындагы чараларны гамәлгә ашыруны күздә тотучы Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәгән өчен, әгәр дә бу хокук бозуларда җинаять җаваплылыгы гамәлләре булмаса яисә алар Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә

административ җаваплылыкка китермәсә, –

кисәтү ясала яисә гражданнарга – бер меңнән алып дүрт мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – унбиш меңнән алып кырык мең сумга кадәр; юридик затларга ике йөз меңнән алып өч йөз мең сумга кадәр административ штраф салына.

2. Шул ук гамәлләрне (гамәл кылмауларны) кабат кылган өчен –

гражданнарга – биш мең сум күләмендә; вазыйфаи затларга – кырык меңнән алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга өч йөз меңнән алып биш йөз мең сумга кадәр административ штраф салына.»;

2) 7.1 статьяда «2.11 – 2.20» саннарын «2.11 – 2.21» саннарына алмаштырырга;

3) 8.1 статьяда:

а) 4 өлештә «Кодексның» сүзеннән соң «2.21,» саннарын өстәргә;

б) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Әлеге Кодексның 2.21, 3.6 (Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге норматив хокукый актлары белән билгеләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда) статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләрне Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының вазыйфаи затлары төзи.»;

в) 10 өлештә «3.10 статьясында» сүзләрен «2.21, 3.10 статьяларында» сүзләренә алмаштырырга;

г) 14 статьяда «2.19, 2.20» саннарын «2.19 – 2.21» саннарына алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 10; 2014, № 7; 2015, № 3, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш), «2.19, 2.20» саннарын «2.19 – 2.21» саннарына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 67-ТРЗ